# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Урта Тигәнәле торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2025 елның 11 ноябрендәге 2 номерлы**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына,Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 18 нче статьясына туры китереп

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Урта Тигәнәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган, МХО да катнашучылардан тыш, 2026 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- су белән тәэмин итү һәм агынты суларны агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта, Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Урта Тигәнәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Урта Тигәнәле авыл җирлеге Башлыгы И.К.Хаматвәлиев